| | |
|---|---|
| СОВЕТ ПОПОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОПОВКА<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2024 г. с.Поповка №122

Карарга үзгәреш кертү турында
Поповка авыл җирлеге Советы
Баулы муниципаль районы
«Җир салымы турында» 2020 елның 10 декабрендәге 5 номерлы

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Попов авыл җирлеге Советы КАРАР:

1. «Җир салымы турында» Баулы муниципаль районының Попов авыл җирлеге советы карарына (18.02.2021 №13, 05.12.2022, № 62, 29.05.2023 №80, 10.10.2023 №93 кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 һәм 3 пунктчаның 2 пунктында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) торак-коммуналь комплексының торак фонды һәм (яисә) инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлегеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш, әлеге абзацта күрсәтелгән эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән)

җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш;

3) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата әлеге абзацта күрсәтелгән, кадастр бәясе һәрберсенең 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән тыш;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль районының bavly.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм чираттагы салым чорының 1 нче санынннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Совет башлыгы, рәисе
Поповка авыл җирлеге С.А. Попов